*декабрь, 2019 ел*

# Гимназия сулышы №2

***25-нче гимназия укучылары газетасы***

## Укытучылар тәҗрибә уртаклаштылар

Икенче чирек вакыйгаларга бай булды. Шундыйлардан 22 ноябрьдә булып узган « Белем бирүнең сыйфаты: актуаль сораулар һәм инновацияләр» темасына фәнни-практик конференция иде.



Конференциягә республиканың төрле төбәкләреннән: Алабуга, Сарман, Зәй, Норлат, Мамадыш һәм шәһәр мәктәпләреннән укытучылар килгән иде. Гимназия укытучылары 1-11сыйныфларда унбер ачык дәрес күрсәттеләр һәм педагогик тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгында мастер – класслар белән чыгыш ясадылар.



Әйтергә кирәк, республиканың төрле төбәк



ләреннән килгән укытучылар безнең гимназия укучылары белән дәрес үткәрүдән уңай тәэсирләре белән уртаклаштылар.

**Якупова Гүзәл**

# Китапханә яңалыклары

Гимназия китапханәсе укучыларның яраткан урыны. Биредә төрле кызыклы чаралар үткәрелә.



Яңалыкларны белү өчен китапханә мөдире Резедә Вәзир кызына берничә сорау белән мөрәҗәгать иттем. Ул дистә елга якын китапханәдә хезмәт күрсәтә, үз эшен белеп, яратып башкара.

– Резедә Вәзировна, китапхәнә яңалыклары турында сөйләгез әле.

– Безнең китапханә залында истәлекле чараларга багышланган чаралар әледән-әле булып тора. Мәсәлән, мәктәп китапханәләре көненә багышлап «Китаплар сабантуе» үткәрелде.



3 В сыйныфы укучылары төрле ребуслар, кроссвордлар чишүдә ярыштылар. «Иң оста әкият язучы» бәйгесендә бүләкләр дә алдылар.

– Хәзерге вакытта нинди китап күргәзмәләре эшли?

- 2020 нче елда Татарстан АССР оешуга 100 ел тулуга карата күргәзмә эшләнде.



Анда республикабыз тарихына карата китаплар, фотолар, газета һәм журналлар урын алган. Шулай ук укучылар Татарстанның күренекле шәхесләре турында күп

мәгълүмат ала алалар. Китап укучылар рус шагыйре М.Ю.Лермонтовның тууына 205 еллыгына карата күргәзмә белән таныша алалар. Бу күргәзмә 8-11 сыйныф укучыларына иншалар, реферат эшләре язганда зур ярдәмче булыр, минемчә.

– Ә китапханә фонды ничек тулыландырыла?

- Әле күптән түгел «Китапка - яңа тормыш» акциясе булып үтте. Гимназия укучылары, укытучылары китапханәгә йөзләгән китап бүләк иттеләр. Бу - фантастик һәм мажаралы әсәрләр, детективлар, балалар өчен иллюстрацияле китаплар. Акциядә катнашучыларга барысына да зур рәхмәт!

- Кызыклы әңгәмәгез өчен, рәхмәт. Китапханә юлыннан укучылар өзелмәсен!

Бакирова Алия

**Юлда сак булырга кирәк!**

Юл йөрү кагыйдәләрен һәрвакыт истә тотарга кирәк. Кагыйдәләрне үтәмәү бик аяныч хәлләргә китерергә мөмкин. Без -5 В сыйныфы укучылары китапханәче Резедә Вәзировна белән транспортка утыру һәм төшү, велосипедта йөрү кагыйдәләрен белүне тикшердек..Ә моның өчен төрле «тукталышларны» үттек. «Вокзал»да булдык, «театр»га кереп чыктык, соңгы тукталыш- «мәктәп»тә безгә кагыйдәләр язылган укучы көндәлеге бүләк иттеләр.

Гарипова Алия





# «Яшь армиячеләр» булдык .

«Яшь армиячеләр» хәрби-патриотик хәрәкәте РФ Оборона министры Сергей Шойгу инициативасы белән оештырылган.  Хәрәкәтнең төп максаты үсеп килүче буында Россиянең хәрби үткәненә ихтирам тәрбияләү, илнең хәрби данын саклау һәм яклауга юнәлтелә.



**Ватан геройлары көне уңаеннан, 8 нче Д сыйныфы укучылары тантаналы төстә яшь армиячеләр сафына кабул ителделәр.**

«Ватанга тугъры калырга, яшь армиячеләр туганлыгына тап төшермәскә, намуслы һәм гадел булырга, ярдәмгә мохтаҗларны якларга, укуда һәм спортта уңышларга ирешергә!" Укучылар бер-бер артлы әнә шундый ант сүзләрен кабатладылар. Ант биргәннәрнең барысы да яшь армиячеләр отрядына керделәр.

"Бүген биргән антыгыз сезнең йөрәкләрдә гомер буена истә калырлык вакыйга булып калачак", - дип билгеләп үтте яшь армиячеләрне сәламләү сүзендә Түбән Кама МЧС бүлеге хезмәткәре Владислав Корсаков..

**Без бергә**



Ноябрьдә шәһәр күләмендә “Без бергә» балалар иҗаты фестиваль-бәйгесе үткәрелде.

Максаты Татарстан Республикасы мәктәпләрендә укучы балалар һәм яшүсмерләрнең нәфис-эстетик иҗатын үстерү, Россия халыкларының  традицияләрен дәвам итү, милли кыйммәтләргә сакчыл караш, хөрмәт тәрбияләүгә юнәлтү.

Безнең гимназиянең бер төркем укучылар коллективы фестивальдә фольклор композиция белән чыгыш ясады һәм икенче урынга лаек булды. Эчтәлекле, матур чыгышны әзерләүдә һәм балаларның артистлык сыйфатларын үстерүдә укытучылар ГыймрановаЗәрия Мөгавый кызы һәм Идиятуллина Гүзәл Йосыф  күп көч куйган.

**Без - коррупциягә каршы!**

«Коррупция. Бу тема бүгенге бик көндә актуаль. Коррупция ул ниндидер феномен. Аның кайдан килеп чыгу серен эзләп табу бик авыр. Бу темага бүгенге көндә Россия президенты Владимир Путин һәм Татарстан президенты Рөстәм Миңнеханов та бик зур игътибар итәләр. 2008 нче елның 25нче декабрендә Россия Федерациясендә “Коррупциягә каршы көрәш”турында закон кабул ителде. Бу законда коррупциягә каршы көрәшнең төп принциплары, коррупцияне хокукый яктан кисәтү һәм хокук бозуларның нәтиҗәсен ликвидацияләү каралган», – дип башлады сүзен сыйныф җитәкчесе Аслямова Гүзәл Заһретдин кызы..
Без сыйныф сәгатендә элеге темага карата видеофильм карадык, викторина сорауларына җавап бирдек. Сыйныф сәгатендә мин шуны аңладым: коррупция – законсыз юл белән кешеләрдән акча алу, акча җыю. Бу – начар .
Аңа каршы көрәшергә кирәк.
Зәйналова Ралина










**Тел белү Кытайга илтә**

Октябрьдә фәннәр буенча  узган олимпиадаларда гимназиянең 10 Б сыйныфы укучысы Гайнетдинова Нәринә кытай теленнән көчен сынап карады һәм муниципаль турда призёр булды. Нәринә кытай телен мөстәкыйль өйрәнә.



Шәһәрдәге «Телләр үзәге» нә ике ел йөреп укытучысы ярдәмендә ул бу көнчыгыш телен  шактый өйрәнгән.  Узган елда Кытайга әнисе белән барган сәяхәт аңа бик ошаган. Ул Кытайның көньягында урнашкан Хайнань утравында һәм Санья шәһәрләренең искиткеч архитектура истәлекләре янында фотога да төшкән. Ни өчен нәкъ кытай телен өйрәнергә булдың дигән сорауга Нәринә болай дип җавап бирде: « Булачак һөнәрем лингвистика белән бәйле булыр дип уйлыйм.Ә кытай теленә килсәк, бу тел дөньяда беренче урынны алып тора. Аннары бу илнең мәдәнияте, менталитеты мине үзенә җәлеп итте.» Язмамны тәмамлап Нәринәгә үзенчәлекле телнең нечкәлекләрен өйрәнүдә уңышлар телим.  Ә үзем шундый нәтиҗәгә килдем: «Тырышсаң кытай телен дә өйрәнеп була икән! » Хәйруллина Диләрә



## Яңа елны көткәндә.



**Яңа ел бәйрәмен өлкәннәр дә, балалар да ярата. Ул бала чакны искә төшерә, ямь-яшел бөдрә чыршы, кәгазьдән ясалган кар бөртекләре, ялтыравыклы шарлар белән хәтергә уелып калган. Һәр кеше Яңа елны көтә, бигрәк тә балалар.Чөнки мәктәп укучыларын кышкы яллар көтә. Түбән Кама шәһәренең чыршы мәйданчыклары бәйрәмгә әзер. Аларның кайсына барып күңелле ял итәргә - сезгә сайларга, кадерле дуслар ! Фотоларга күз төшереп алыгыз әле. Минемчә, шәһәребезнең чыршы мәйданчыклары искиткеч матур!**

**Кадарле дуслар! Сезне Яңа 2020 нче ел белән котлыйбыз. Яңа ел һәммәгезгә дә шатлык-куанычлар китерсен. Һәр йортка, һәр гаиләгә уңышлар гына алып килсен. Күңелегез саф, хыялларыгыз якты һәм матур булсын!**





Редактор: Якупова Г. Проект җитәкчесе: ШараповаН,Н. Хөрмәтле укучылар, яңалыкларыгыз , тәкъдимнәрегез булса 3023001035@edu.tatar.ru электрон адресына җибәрә аласыз.